ДОГАЛЫ ҖИР

Патриарх Татарстанны нәрсә өчен мактаган?

> 2

ЧЕП-ЧЕП-ЧЕП, ДИЛӘР

Арчадан Рәзимә һәм Радик Бариевлар кош-корт үстерү серен яхшы белә

> 3



ТАНЫШУ ЧАТЫ

Татарча «Тиндер» бармы?

> 3



ХА-ХА-ХАНӘ

Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – биредә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 70 (29037) | Шимбә | 20 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ХӘЛӘЛ АЛЫШ-БИРЕШ

Бер якта – Иран тәм-томнары, икенче якта – Сенегал кием-салымы. Татарстан уңганнарының сәүдә рәтләре. «Казан» агросәнәгать паркына кеше болай да бик яратып йөри, бу көннәрдә исә андагы халыкның саны бермә-бер арткан. Сатучылар моңа сөенеп туя алмый. Җитмәсә, башка илләрдән килгән сәүдәгәрләр белән дуслашып калырга мөмкинлекләре бар. «ВТ» хәбәрчесе, 18–21 май көннәрендә уза торган хәләл ярминкәгә барып, андагы хәлләрне күреп кайтты.

«Russia Halal Market 2023» ярминкәсе «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» XIV Халыкара икътисадый форумы кысасында эшли. Оештыручылар монда Иран эчемлекләре, Төркия тәм-томнары, Сенегал кием-салымы да сатып алып булачагын вәгъдә иткән иде. Татарстан җитештерүчеләре белән бергә җәмгысы 400ләп хәләл сәүдә ноктасы үз товарын тәкъдим итте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сенегалдан – Иранга

Беренче эш итеп, ярминкәдәге иң чуар почмакка тукталдык. Сенегалдан ук килгән ханымнар аллы-гөлле төсләрдәге кием-салым, төрле бизәнү әйберләре белән үткән-сүткән ханымнарны кызыктырып торды. Иң күп кеше шулар янында иде.

– Казан – искиткеч шәһәр! Сенегалда яшәүчеләрнең 95 проценты – мөселманнар. Әлеге чарага да без тәҗрибә алмашу, Татарстан, шулай ук мөселман илләре һәм Сенегал арасында күпер салу өчен килдек. Без Сенегалдагы «Калинка» рус мәдәни үзәге белән хезмәттәшлек итәбез, киләчәктә Татарстан белән дә эшләрбез дип өметләнәбез, – дип сөйләде алар «ВТ» хәбәрчесенә.

Ә борынны ярып кергән тәмләткечләр исе Ираннан килгән җитештерүчеләрнең сәүдә ноктасына тартып китерде.

– Монда без Иранда җитештерелгән продукцияләрне: төрледән-төрле эчемлекләр, тәмләткечләр, киптерелгән җиләк-җимешләр тәкъдим итәбез. Әлеге чарада катнашу безнең өчен бик мөһим. «Казан» агросәнәгать паркында эшләү Татарстан базарына чыгарга ярдәм итсә, әлеге форумда катнашуыбыз Россия базарында эшләргә мөмкинлек бирә, – диде Фәридун Камолов.

Агропаркны аркылыга-буйга күпме иңләп йөрсәк тә, оештыручылар вәгъдә иткән төрек тәм-томнарын таба алмадык. Дөресрәге, алар монда болай да бар, ә «Russia Halal Market 2023» ярминкәсенә атап килүче төрек сатучылары күренмәде. Казаннан Әлфия апа да шуңа аптырап йөри иде. Алай да, ярминкәдән бик канәгать калган ул.

– «Яңалыклар»дан ишетеп килдем. Мин әйтәм, күптән агропаркта булганым юк, бер йөреп кайтыйм. Өйлә намазына кадәр кайтып җитәргә кирәк, – дип сөйләде ул безгә. – Бик күркәм, бик пөхтә итеп эшләгәннәр. Ике сумка товар җыйдым. Төрекләр дә була дигәннәр иде, күрмәдем. Тәмләткеч, чәй ише вак-төяк алырмын дигән идем.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Рөстәм Гайнуллов аңлатканча, әлеге хәләл ярминкәдә күбрәк Татарстанда җитештерелгән продукцияне күрсәтү максат булган. «Сәбәбе – без Татарстанны хәләл продукциясе экспорты өчен тәҗрибә уздырыла торган төбәк буларак тәкъдим итәбез», – дигән иде ул.

Татарстанныкын сайла...мы?

Янушевлар гаиләсе Мари Иленнән килгән. Юк, сатучы түгел, сатып алучы алар. Зур кызыксыну белән дини китаплар карап басып торалар иде.

– Ислам дине белән кызыксына башлагач та, Татарстанга бару теләге белән яндык. Аеруча Болгарны күрәсебез килә иде. Әлеге форум турында ишеткәч, өч көнгә Казанга килдек. Монда әйтеп-аңлатып бетерә алмый торган мохит икән, – дип сөйләде гаилә башлыгы.

Җиләк-җимеш сатучы Гөлшаной Туктамуратова сүзләренчә, агропаркны һәм сатучыларны ай ярым тирәсе алдан шушы чарага әзерли башлаганнар. Сатучыларга шәригать кануннары буенча алыш-биреш кагыйдәләрен аңлатканнар.

– Хәләл ярминкә булгач, барлык сатучыларны да алдан әзерләделәр, тикшерделәр. Хәер, без болай да көн саен лаборатория тикшерүе узабыз, – диде биш ел дәвамында бер урында сәүдә итүче ханым. – Башка вакыт белән чагыштырганда, кеше бик күп. Күбесенчә, нинди чара икән бу, дип кызыксынып киләләр дә сумкаларын тутырып кайтып китәләр *(көлә)*. Безнең өчен бу – уңай күренеш, әлбәттә.

Татар милли стилендә эшләнгән яулыклар бренды хуҗасы Елена Габдрахманова исә, Татарстан җитештерүчеләренә башка илләрдән килгән кунаклар белән аралашырга мөмкинлек булмады, дип борчыла.

– Без бу чараны ел буе көттек. Милли горурлыгыбыз булган бизәкләребез төшерелгән яулыкларны «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә күрсәтергә өметләнгән идек. Әмма безгә бернинди мәгълүмат бирүче дә булмады. Өстәвенә анда сатарга керү өчен шактый зур сумма акча түләргә кирәк булып чыкты. Без генә түгел, башка җитештерүчеләр өчен дә кыен аны түләү. Шул рәвешле, Татарстан эшмәкәрләренә экспортка, халыкара хезмәттәшлеккә чыгу юлын чикләделәр. Әмма бу зарлану түгел. Шөкер, сыр-колбасалар янында булса да, сату-алу эше бик яхшы бара, – диде ул безгә.

Чыгым арта

Татарстанда минималь куллану бюджеты (кешегә бер айда иң кирәкле товарлар сатып алу, мәҗбүри түләүләр өчен кирәкле чыгым күләме) арткан. Министрлар Кабинеты карарында быел беренче квартал өчен ул 21805 сум күләмендә расланган. Чагыштыру өчен: узган елның октябрь – декабрендә бу күрсәткеч 21142 сум булган. Шул рәвешле ул 3,1 процентка, ягъни 663 сумга үскән. Узган елның өченче кварталында минималь куллану бюджеты 21037 сум тәшкил иткән. 2022 елның апрель – июнендә исә 21300 сум күләмендә расланган. Ә беренче кварталында 19424 сум булган. Күрсәткеч бер ел эчендә 2381 сумга, ягъни 122 процентка арткан.

Сүз уңаеннан, минималь куллану бюджеты яшәү минимумы күләмен исәпләүдә кулланыла.

Исемлек булдырыла

Быел илдә мохтаҗлар реестры булдырылачак. Проект киләсе елның башыннан гамәлгә ашырыла башларга тиеш. Россия вице-премьеры Татьяна Голикова әйтүенчә, бу катлаулы бурычны хәл итү берникадәр кичектерелгән. Реестрны эшләтеп җибәрү өчен, башка институтлар булдыру кирәк булган чөнки.

Голикова сүзләренә караганда, мондый исемлек чын мәгънәсендә мохтаҗ кешеләрне билгеләү, шулай ук мәгълүматларны Росстат күрсәткечләре белән чагыштыру мөмкинлеге бирәчәк.

Вице-премьер искәртеп үткәнчә, хәзерге вакытта Россиядә 35 миллион кешегә 31 социаль ярдәм чарасы күрсәтелә. Быел шуңа тагын 11 чара өстәләчәк.

Кораб суга төшә

«Ак Барс» суднолар төзү корпорациясе ел азагына кадәр водород ягулыгында эшләүче тәүге пассажир корабын төзүне төгәлләп, суда сыный башлауны күздә тота. Корпорация генераль директоры Ренат Мистахов әйтүенчә, корабның «гәүдә»се төзелеп беткән инде. Хәзерге вакытта эчке бизәү эшләре алып барыла.

Ул транспортның экологиягә зыян китерми торган төрләрен үстерергә кирәклеген билгеләп үткән. Мистахов әйтүенчә, корпорация алга таба да, әйләнә-тирә мохиткә зарарлы матдәләрне азрак чыгару максатында, водород ягулыгы һәм электр кулланып йөзүче кораблар төзеячәк.

Бишенче тапкыр озайтыла

Яз башыннан бирле Татарстан урманнарында янгын куркынычы турында кисәтү бишенче тапкыр озайтыла. Гидрометеоүзәк мәгълүматлары буенча, кисәтү 29 майга кадәр дәвам итәчәк.

Бу чорга республика урманнарында югары дәрәҗәдәге (IV класслы) янгын куркынычы билгеләнгән. Көнчыгыш районнарда урыны белән гадәттән тыш куркыныч (V класслы) көтелә.

Исегезгә төшерәбез: быел язын урманнарда югары дәрәҗәдә янгын куркынычы турында кисәтү 13–20 апрель чорына игълан ителде. Шуннан соң ул 21–26 апрельгә һәм соңрак 27 апрель – 2 майга, 3–10 майга, 11–19 майга кадәр озайтылды. Республикада 17 апрельдән 10 майга кадәр янгынга каршы махсус режим гамәлдә булды. Бу чорда учак кабызу, чүп-чар яндыру рөхсәт ителмәде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Вакыйга

Акланган өмет

«РОССИЯ – ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ» ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАДЫЙ ФОРУМЫ: НӘТИҖӘЛӘР СӨЕНДЕРӘ

«Безгә мондый мәйдан бик тә кирәк иде!» Татарстан башкаласында узган «KazanForum»ны җыен кунаклары әнә шулай бәяләде. Форумда 85 чит илдән, Россиянең 84 төбәгеннән 16 меңгә якын кеше катнашты. Ул алдан фаразлаганнан да яхшырак нәтиҗәләр биргән.

Төрле юнәлештәге 200 чара, 150дән артык эшлекле сөйләшү, чит ил делегацияләре белән ике яклы 7 очрашу. Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина икътисадый җыен тәмамланганчы ук аның кайбер йомгакларын әйтте.

– Чараның нәтиҗәлелеге имзаланган килешүләр һәм аларның саны белән билгеләнә, әлбәттә. Без йөзгә якын килешү имзаларга ниятләгән идек. Алдан ук шуны әйтә алам: без әлеге чикне уздык, – диде ул.

Россия Премьер-министрының беренче урынбасары Андрей Белоусов форумның быелдан федераль статус алуын да искәртте.

– Җыен шаккатыргыч нәтиҗәләргә иреште. Без әлеге мәйданга карата зур кызыксыну булуын күрәбез. Җыенга Иран, Малайзия, Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре кебек илләрдән зур делегацияләр килгән. Биредәге эшлекле кәефтән чыгып, ул үз-үзен тулысынча аклады дип әйтә алам. Безгә мондый мәйдан бик тә кирәк иде, – диде Андрей Белоусов.

Фикер

Россия Премьер-министры урынбасары Марат ХӨСНУЛЛИН:

Бу – бик вәкиллекле җыен. Чарага 16 меңгә якын кеше килгән. Кунакларның исемлеген карап чыктым: бөтен Урта Азия, Якын Көнчыгыш илләре министрлары, Хөкүмәт җитәкчеләре дәрәҗәсендәге саллы делегацияләр килгән. Бу мөселман илләренең Россиягә карата игътибары зур булуы турында сөйли. Шуны да искәртеп әйтәсем килә: бер генә мөселман иле дә безгә каршы санкцияләр кертмәде һәм Көнбатыш илләре керткән санкцияләрне хупламады. Димәк, мөселман илләре – безнең ышанычлы хезмәттәшләребез.

Форумда күтәрелгән төп мәсьәләләр арасында логистиканы җайга салуны билгеләп үтте ул.

– Бу көннәрдә генә Тәһранда Россия белән Иран арасында «Төньяк–Көньяк» транспорт коридорының төп өлеше булып саналган Көнбатыш өлешен төзү турында килешү имзаланды. Форум кысасында да Азәрбайҗандагы хезмәттәшләребез белән әлеге коридорны эшләтеп җибәрү өчен кирәкле тәгаен адымнар турында сөйләштек. Бу транспорт коридоры бөтен Евразия төбәге өчен зур әһәмияткә ия, – диде Россия Премьер-министрының беренче урынбасары.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Айрат ФӘРРАХОВ, Россия Дәүләт Думасы депутаты:

Россия даруханәләре ни дә булса җитештерәме-юкмы – без әнә шуны ачыкладык. Әмма нәтиҗә канәгатьләнерлек булмады. 500дән артык даруханәнең моңа рөхсәте булса да, берни җитештерми. 643 даруханә җитештерә, әмма җитәрлек дәрәҗәдә түгел.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЭШ ЭЗЛӘҮ

Ил халкының яртысы диярлек якын арада өстәмә эш табарга тели. Бу хакта «Работа.ру» һәм «Подработка» хезмәтләре мәгълүматлары сөйли.

КАЙДАН ЭЗЛИСЕЗ?



ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

«Үрчү» дигән бәла

Бер ай чамасы гына элек мәгълүмат чаралары Һиндстанның халык саны буенча Китай чаклы Кытайны узып киткән белдергән иде. Соңгы араларда ул хәлнең сәбәпләрен ачыкларга тырышалар. Ничек инде Китай беренчелекне башка илгә биргән? Беренче сәбәп, миңа калса, шунда: Европа «чир»е, бала азлыкны алга сөргән алдынгы илләр менталитеты инде ерак Кытайга ук барып ирешкән. Берничә дистә ел элек кенә ашкынып үрчегән халык бүген бала табарга атлыкмый башлаган. Европадагы тормыш дәрәҗәсенә әлегә ерак булса да, комфорт, туклык, башлап үзең өчен яшәү кебек сыйфатлардан торган винегретның түмән алар да үз иткән, димәк.

Китайда «Бер гаилә – бер бала» кагыйдәсен, ягъни үрчүне тыюны бетергәнгә 7–8 елдан да артык түгелдер. Узган гасырның җитмешенче еллары азагында кабул ителгән андый канун Китай икътисадының ул замандагы зәгыйфьлеге чамасыз үрчегән халыкның тамагын туйдыра алмауга бәйле булса, хәзер хәл гел башка. Соңгы ике дистә елда күтәрелеп киткән тормыш сыйфаты һәм «акыл керү» аларны да ярыйсы «бозган» булып чыга. Үзең өчен, үзеңне генә кадерләп, үз көеңне көйләп яшәгәндә, бала-чаганың мәшәкать чыганагы икәнен аңлаганнар. Баланы, табудан да бигрәк, үстерергә, укытырга, аякка бастырырга кирәк бит. Ә алай эшләү, кайсы яктан гына карама, үзеңне чикләү инде ул. «Бер гаилә – бер бала» принцибы шул сәбәпле кытайлыларга, күрәсең, ошап киткән. Язуларына караганда, бүген анда бала табучы һәр 10 хатынга барысы 12 сабый туры килә. Шундый вазгыятьтә халык саны артмау – бер хәл, белгечләр ул илдәге депопуляция – кимү хакында да сөйли башлаган.

Ә бит бер караганда, андый хәлләрдә бер трагедия дә юк. Җир йөзендә болай да 8 миллиард кеше яши. Бер гасыр элек ул санның чиреге генә (1927 елда – ике миллиард) булган. Без бит пробиркада махсус үрчетелүче микроорганизмнар, куян фермасындагы куяннар түгел, нигә артыгын күбәергә? 8 миллиард кешенең һәрберсенең тамагы бар, аны туйдырырга кирәк. Һәр адәми затның тораклы буласы, автомобильдә җилдерәсе килә. Торакны, бүгенге «человейник»ларны, таш джунгли – мегаполисларны зурайтып тезәргә кирәк. Ә чын джунглилар майданы кими бара. Гомумән, җир һәм аның ресурслары чиксез түгел. Кеше заты аларны ел саен күбрәк алырга, алмашка берни дә бирмәскә күнеккәндә бигрәк тә. Язуларынча, автомобильләр саны да планетада инде 1,5 миллиардка якынлаша. Аларның һәрберсе күпләп бензин, солярка яндыра, дистәләгән кеше суларлык кислородны йотып, һавага углекислота ыргыта. Нефтьне генә кешелек хәзер елына 4,2 миллиард тонна (!) чыгара. Чыгара һәм төрле рәвешләргә китерен яга. Кешелек, бу яктан караганда да, үзе хакында, бүгенге көн хакында гына кайгыртучы үтә дә мин-минлекле цивилизация булып кала: үрчи, арта, көннән-көн күбрәк куллана, таләп итә. Ә бит кеше саны, мәсәлән, ике тапкыр кимрәк булса, шул ук җир мае да, ихтимал, ике тапкыр ким табылып, атмосфера, табигать күпкә азрак пычраныр иде. Бу урында кызыклы бер нәтиҗә килеп чыга: бәндәдәге «бер гаилә – бер бала» рәвешендәге шәхси эгоизмда кешелекнең глобаль эгоизмын җиңәрлек, планетаны җиңел сулатырлык көч, потенциал бар кебек.

Тик менә «дәүләт» дигән берләшмәләрнең, аларның кубесенең үрчү-үрчемәү дигәндә үз мәнфәгатьләре, үз мин-минлеге бар. Бик күп дәүләтләр халык саны кимүдән уттан курыккандай курка. Ченки халык кимегәндә, икътисадый күрсәткечләр дә аска тәгәри. Шул ук эчке тулай продукт (ВВП), мәсәлән. Мисал өчен, Китай, 1,4 миллиардлы халкы булмаса, кеше саны 120–130 млн булган Японияне – ике дистә елдан артык дөньяның икенче икътисады булган илне абсолют күрсәткечләр буенча уза алыр идеме? Әлбәттә, юк. Китай, икътисад дигәндә, АКШның үзен куа, аның белән ярыша икән, бигрәк тә баш санының роле бик зур. Дөньяда иң зур армия дә – кытайларда. Эшчеләр, төрле өлкәләрдәге белгечләр саны буенча да алар беренче. Кеше капиталы дигәндә, ул бит әле – сыйфат кына түгел, сан да. Һәм инде менә Американы куып барганда, кайчан да булса узарга өмет тотканда гына шундый «чир», тормыш яхшыру китергән шундый «эпидемия». Бераздан аларда да ана капиталы кертмәгәйләре.

Дәүләтләр, аларның җитәкчеләре арасында икътисадый, хәрби гайрәт буенча күптән килгән узара ярышның шушы көнгә кадәр тукталганы юк. Абсолют күрсәткечләр буенча булса да алда барырга тырыша алар. Халык санына таянганда «алдынгылык» җиңелрәк тә бирелә. Җир йөзендәге илләрнең азы гына халыкның тормыш сыйфаты, аның югарылыгы дип җан ата. Шул ук Төньяк Европа илләренә, мәсәлән, абсолют күрсәткечләр кирәкми, алар депопуляция белән дә инде күпмедер килешкән. Ә зур илләр, геосәясәт белән мавыкканнар, глобаль икътисадта алда торырга тырышканнар, бигрәк тә аларның авторитар булганнары киресенчә кылана.

Һиндстан – Китай белән чагыштырганда фәкыйрьрәк, халкы караңгырак дәүләт. Халык саны буенча 1,4 миллиардлы Китайны узуда, ихтимал, шул ике сәбәп төп рольне уйнагандыр. Әйткәнебезчә, кайда цивилизацияле заманча тук һәм уңайлы тормыш, кайда заманча мәгърифәт, аң-белем – шунда үрчү кими. Җирдә кеше саны арту әлегә Африка кыйтгасы, Көньяк Азиянең фәкыйрь дәүләтләре, шул ук Һиндстан хисабына бара. Цивилизация нык үткән тарафларда баш саны арту йә туктаган, яки кирегә юналгән. Демографик проблемалар «Китай икътисадый яктан АКШны куып җитәчәкме?» дигән сорауга уңай җавап бирүне бик кыенлаштыра. Китайның, Америкадыкы кебек, башкаларга көчле икътисадый йогынтысы да, доллар пирамидасы төсле, башкаларны савуга юнәлтелгән финанс корылмасы да, америкаңнардагы кебек фәне дә юк. Депопуляция, бала аз табу трендына исә, кеше аңына бер уттеме, процессны кирегә борам димә.

Проблема микән соң ул? Кеше кавеме, дигәндә аңа депопуляция кирәклеге ачык ич. Кимү, оптималь санга чыгу. Бары шул чагында гына без моңарчы җыелып килгән күпсанлы проблемалардан котыла алачакбыз. Депопуляция юлына киндидер эпидемия, пандемия, сугышлар аша түгел, ә алда искәртелгән рецептлар аша чыгу мәслихәтлерге дә ачык. Караңгылыктан, фәкыйрьлектән котылсаң да аерым дәүләтләрнең кирелеген, мин-минлеген генә җиңәсе.

КЫЙММӘТЛӘРНЕҢ КЫЙММӘТЕ

Марк Аврелий белән «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеменең Казанда узган чираттагы утырышын нәрсә бәйли? Баксаң, фикер сөрешләренең уртаклыгы икән.

patriarchia.ru

Заманында Рим императоры: «Рухи кыйммәтләрне санга сукмау һәм әхлакый яктан түбән тәгәрәү бөек империянең җимерелүенә китерде», – дигән. Утырышта катнашучыларның былел җыелып сөйләшүләре дә традицион кыйммәтләргә һәм аларның узара хезмәттәшлектәге роленә багышланган иде. Чарада катнашучыларның чыгышлары да әлеге мәсьәләнең мөһимлегенә бәйле булды. Яңгыраган фикерләрне без дә ишетеп кайттык.

Традицион кыйммәтләрне саклау, диннәр һәм халыклар арасындагы дуслык дигәндә, Татарстанны үрнәк итеп куярга була. Утырышның төп кунакларының берсе – Мәскәү һәм бөтен Русь Патриархы Кирилл да шундый фикердә. «Бәлки, Россиядәге башка бер генә урын да төрле кешеләрнең ил, халкыбыз файдасына узара нәтиҗәле эшчәнлек алып бару символы булып тормыйдыр. Казанда мәчетләр белән гыйбадәтханәләр янәшә тора, монда христианнар һәм мөселманнар бергә уртак файдага эшлиләр», – диде ул.

Мәскәү кунагы белдергәнчә, Рус православие чиркәве мөселманнар белән юкка гына тыгыз элемтәдә тормый. «Безнең нигез булган кыйммәтләребез охшаш, хәтта бер үк. Православие вәкилләре дә, мөселманнар кебек үк, Алла кушканча эшләргә омтыла. Без ихлас мәгънәдә консерватив. Православие вәкилләре дә, мөселманнар да гөнаһны норма буларак карауга каршы чыга. Без әхлакый кыйммәтләрне саклар, мәрхәмәт, хөрмәт идеалларына ияреге тиеш», – диде рухани.

Татарстан Рәисе, төркем җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов исә Ислам илләре белән хезмәттәшлек итүнең мөһим юнәлешләренә тукталды. Хәзерге вакытта эшлекле мөнәсәбәтләрне алга таба нығытуның иң мөһим факторы – халыкара сәясәтнең төп мәсьәләләре буенча фикерләрнең туры килүе. «Утырыш традицион рухи кыйммәтләрне ныгытуга, исламофобия, ксенофобия, экстремизм, террорчылык белән көрәштә өлеш кертер», – дигән фикердә Рөстәм Миңнеханов.

Утырышта чыгыш ясаучыларның фикерләре уртак иде. Алар стратегик күзаллау төркеменең көн кадагында торган теманың хәзерге сәяси шартларда актуаль булуын билгеләп үтте, киләчәк буын кешеләренең йөрәкләрендә традицион диннәрнең рухи-әхлакый кыйммәтләрен торгызу аша гына узара аңлашуга, туганнарча хезмәттәшлеккә ирешеп буласын әйтте.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

АКЛАНГАН ӨМЕТ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Россия Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин әйтүенчә, форум икътисадый яктан зур кызыксыну уята.

– Бигрәк тә логистиканы җайга салу юнәлеше мөһим. Бүген «Төньяк–Көньяк» транспорт коридоры бөтен илләрне дә кызыксындыра диярлек. Иран, Бәхрәйн, Фарсы култыгы илләрен аласыңмы – барысы да бу мәсьәләдә кызыксыну белдерә. Безнең хәләл продукциягә, мәсәлән, авыл хуҗалыгы товарларына, хезмәтләр күрсәтүгә сорау зур, – диде Марат Хөснуллин. – Әйтергә кирәк, без моңарчы күбрәк Көнчыгышка таба үсеш стратегиясенә басым ясадык. Бу эштән бүген дә баш тартмыйбыз. Көнчыгыш тимер юл полигоны, Санкт-Петербург, Мәскәү, Казан, Екатеринбург, Төмән һәм бу юнәлештә Владивостокка кадәр сузылачак юл төзелешләре дәвам итә. Әмма чынбарлык безгә Көньякка таба хәрәкәт итәргә кирәклеген күрсәтте. Көньякка Каспий диңгезе аша чыгу юлын күрәбез. Бу мәсьәләдә Урта Азия делегацияләре белән уртак фикергә килдек. Кайбер илләр белән килешүләр төзедек инде, ә кайбер хезмәттәшләребез белән якын арада ук очрашып сөйләшергә сүз куештык. Бөтен эшне узара сөйләшеп башкарачакбыз.

Россия, шул исәптән Татарстан һәм төрле илләр арасында узара товар әйләнешен озатуга бәйле 100ләп килешү төзелүен дә әйтте ул. Аерым алганда, Чаллыдан Үзбәкстанга көнкүреш техникасын җыйдыра башлаячаклар. «Хайер» компаниясе Үзбәкстанның «Goodzone Trading» компаниясе белән Чаллыда җитештерелүче көнкүреш техникасын әлеге илгә җибәрү турында килешү төзегән. Чаллыдан Үзбәкстанга суыткычлар, кер юу машиналары һәм башка төрле көнкүреш техникасы озата башлаячаклар дип фаразлана.

Әфганстанның якын арада ук «Татнефть» компаниясе белән нефть продуктлары сатып алуга бәйле килешү төзүе ихтимал.

– Безгә якынча 4 миллион тонна нефть продуктлары кирәк. Аның бер өлешен Төрекмәнстан һәм Иреннан алабыз. Россия компанияләре, аерым алганда, «Татнефть» белән дә килешүләр төзергә телибез, – диде Әфганстан сәнәгать һәм сәүдә министры Нуретдин Азизи форумның икенче көнендә.

Россия һәм ислам илләре арасындагы хезмәттәшлекне спорт чаралары белән дә ныгытмакчылар.

– Кайбер илләр һәм халыкара спорт оешмалары үз-үзен тотышы, кыяфәте гайре табигый булган кешеләр өчен да ярышларда катнашуга ишек ачты. Бу Олимпия хартиясе гамәлләрен шик астына куя, дини кануннар белән ярашмый һәм гомумкешелек кыйммәтләренә каршы килә. Шуңа күрә Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасына кергән илләрдә яшәүче 16 яшькә кадәрге спортчылар арасында «Үсмерләр ислам уеннары» үткәрергә тәкъдим итәм, – диде форумда Татарстан Олимпия комитеты президенты Марат Бариев. – Тәүге уеннарны Казанда үткәрергә дигән фикер бар. Россиядә 20 миллионнан артык мөселман яши. Ә Татарстан – илнең иң төньяктагы мөселман төбәге. Бирелә Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләре белән эшләүгә зур әһәмият бирелә.

Хәзерге геосәяси шартларда Россия һәм ислам илләре арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыту турында форумның пленар утырышында да сөйләштеләр.

– Бүгенге шартларда ислам илләре белән мөнәсәбәтләр аеруча зур әһәмияткә ия, – диде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов. – Ислам икътисады дөнья икътисадының мөһим өлеше булып санала. Халыкара сәүдәдә аның тоткан урыны елдан-ел арта. Дустанә ислам илләре куркынычсызлык тәэмин итү, тотрыклылык, глобаль һәм төбәкара дәрәҗәләрдә икътисадый кыенлыкларны хәл итү мәсьәләләрендә елдан-ел илебезнең ышанычлы хезмәттәшләренә әверелеп бара.

Пленар утырышта чит ил вәкилләре, Татарстанның кунакчыллыгына, бирелгә эш өчен тудырылган шартларга соклануын белдерел: «Без сездә тагын берничә көн кунак булырга риза», – дип тә әйтте.

Рөстәм Миңнеханов, озак та уйлап тормыйча: «Бездә генә калыгыз!» – дип җавап бирде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ria.ru

УРТАК КАЛӘМ

Хезмәттәшлек

Карашлар да, эш тә – шул ук. «Татмедиа» агентлыгы һәм Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы Мәгълүмат агентлыклары берлеге меморандум төзеде. Аның нигезендә ике як та бер-берсе белән тәҗрибә уртаклашачак, уртак проектларны тормышка ашырачак.

Меморандумга кул кую «KazanForum» халыкара форумы кысасындагы «Россия – Ислам дөньясы: тотрыклы үсеш һәм икътисадый алгарыш өчен медиахезмәттәшлек» сессиясендә узды. Аны «Татмедиа» агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев һәм Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасының мәгълүмат агентлыклары берлеге генераль директоры Мөхәммәт Абдраббо Альями имзалады.

Рәсми килешүләргә кадәр әлеге сессиядә заманча массакүләм мәгълүмат чараларының үсеш үзенчәлекләре, Россия һәм Ислам дөньясы илләрендәге журналистларның узара хезмәттәшлек юллары турында фикер алышу булды.

Мәгълүмати һөҗүм чорында берләшү бигрәк тә мөһим. «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме рәисе урынбасары, Россия Федерация Советының Халыкара эшләр комитеты рәисе урынбасары Фәрит Мөхәммәтшин белдергәнчә, «кумәк Көнбатыш» игълан иткән мәгълүмати сугыш шартларында журналистларның да, мәгълүмат чараларының да роле күп мәртәбә артты.

Сессия катнашучылары арасында Төркиянең «Анадолу» агентлыгының чит ил тапшырулары баш мөхәррире Эрман Юксель бар иде. Эрман әфәнде массакүләм мәгълүмат чаралары игътибарын исламофобия һәм русофобия белән көрәшкә юнәлтергә чакырды.

– Гел сөйләшергә кирәк булган махсус темалар бар. Исламофобия һәм русофобия дә – шулар рәтендә. Бу мәсьәләләргә бәйле рәвештә мәгълүмат чаралары аерым гамәли караррлар кабул итәргә тиеш, – дигән фикердә Төркиядән килгән кунак. – Соңгы вакытта Россиягә дә, Төркиягә дә мәгълүмати басым арта. Дәүләтләрдәге мәгълүматны дөрес тәкъдим итәргә тиешбез. Начарлыкка күп игътибар бирелә. Уңышларны күбрәк яктыртырга кирәк.

Ядкәрләр кайтты

Сөбханалла!

Кичә «KazanForum 2023» халыкара икътисадый форумы кысасында республикада тарихи вакыйга булды. Дагыстаннан Татарстанга беренче тапкыр Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләренең ядкәрләре кайтарылды.

Мәртәбәле кунакларны Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр эшчәнлеге буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров каршы алды.

– Бу – безнең өчен бик зур вакыйга. Кулыма шушы ядкәрне тапшырып, «Бу –пәйгамбәрнең кылычы», – дигәч, үземне кая куярга белмәдем. Сүзем дә югалды, күзләр дә яшьләнде. Бу әйберләр безне рәсүлебез чорына кайтара. Әгәр дә бер кешене яратсак, якын күрсәк, аңа бәйле булган әйберләрне саклыйбыз, үз итәбез. Пәйгамбәребезнең гаиләсе, сәхабәләренә бәйле булган әйберләр дә безнең өчен бик кадерле, – дип уртаклашты ул хис-кичерешләре белән.

Кыйммәтле хәзинәне Татарстанга алып килгән Дагыстан мөфтиенең урынбасары Мөхәммәдрәсул Саадуев сүзләренә караганда, ядкәрләрне кояш нурлары үтеп керми, махсус температура саклана торган сейфларда кайтарганнар. «Бу ядкәрләргә шундый зур игътибар бирүгезгә өчен зур рәхмәт. Алар безне ислам тарихына алып кайта. Әлеге ядкәрләр мөселманнарның иманын, рухын тагын да ныгытсын», – диде ул.

Ядкәрләрне 21 майда, Изге Болгар җыены ачылышы тантанасыннан соң Болгарның Исталек билгесе бинасында карап булачак. Экспозициядә пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең, аның гаилә әгъзалары һәм сәхабәләренең шәхси әйберләре урын алачак.

Алар арасында Мөхәммәд пәйгамбәрнең май касәсе һәм кылычы, пәйгамбәрнең хатыны Гайшә белән кызы Фатыйманың чүлмәкләре, сәхабәләрнең сәфәрләрдә йөртә торган су савыты һәм көбәсе, пычагы, кул тегермәне да бар. Әйберләр дөньяның, шул исәптән Согуд Гарәбстаны Корольлеге һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре кебек төрле ислам үзәкләре фондларыннан җыелган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

realnoevremya.ru

ТАНЫШТЫРА, КАВЫШТЫРА

ИНТЕРНЕТ АША ТАНЫШЫП, ГАИЛӘ КОРУ МӨМКИНМЕ?

Менә шундый хәлләр

Аралашу, очрашу, кичке уенга чыгу – болар хәзерге яшьләр өчен ят күренеш инде. Хәзер пары булмаган һәр икенче кеше танышу сайтларында теркәлә. Телефоннарга төбәлеп яшәгән заманда үз тиңеңне очратуның иң җайлы ысулы бу. Интернет аркылы танышып, гаилә кору мөмкинме? Татар яшьләре кайда таныша? Без әнә шуларны белештек.

Яшьләрнең виртуаль, җансыз танышу, аралашуларга алдануы, үзләрен акрынлап ялгызлыкка дучар итүе күпләрне борчый. Хәер, прогресс, югары технология заманында яшьләр генә түгел, пенсия яшендәгеләр дә тиң парын танышу сайтларында эзли.

Сер түгел, аларның ниндие генә юк хәзер. Күптән түгел иң популяр булган «Тиндер» кушымтасы Россиядән китүе турында хәбәр иткәч, күпләрдә «Хәзер кайда танышырга?» дигән сорау тугандыр. Дөньякүләм танышу сайтына алмашка үзебезнекеләр килә. Бу сайтлар турында белүчеләр аның кадәр күп булмаса да, алар бар һәм шактый уңышлы эшлиләр. Татарлар өчен махсус кушымталар да бар. Аларның максаты – милләттәшләребезне кавыштыру, традицияләрне саклау. Әйтергә кирәк, аларда тәртиплелек дә шактый контрольдә тотыла. Шундый кушымталарның берсе – «Анаем» проекты. Татар аудиториясе өчен танышу сайты 2014 елда эшли башлаган. Җитди мөнәсәбәтләр, гаилә кору өчен оешкан ул. Монда татарлар, милли традицияләрен саклап, үзләренә тиң яр таба ала. Ул бүген ни дәрәҗәдә популяр? Әлеге платформада танышкан парлар белән сөйләштек.

Казаннан Айгөл Әсәдуллина «Анаем» кушымтасында булачак ире белән 6 ел элек танышкан. Бәхетле пар моннан 3 ел элек никах укыткан, мөнәсәбәтләрен законлаштырган. Хәзер инде бәби дә үстерәләр.

– Иремнең абыйсы да безнең киңәш буенча «Анаем»да теркәлде һәм тиң ярын тапты. Күптән түгел сөйгәне белән никах укыттылар һәм язылыштылар. Мондый мөһим эш алып барылуга без бик рәхмәтле. Татар халкының гореф-гадәтләрен һәм йолаларын сакларга тырышучы кешеләрнең булуы бик яхшы. Аллага шөкер, барыбыз да – мөселманнар. Киләчәк буынга мәдәни кыйммәтләрнең, гореф-гадәтләребезнең мөһимлеген тапшырырга тырышачакбыз. Бу сайт турында күбрәк кеше белсен иде, – дип сөйләде Айгөл.

vk.com

Искәртеп узганыбызча, танышу сайтлары – үзеңә кирәген табуның иң кулай һәм заманча ысулы. Кешеләр хәтта бөтенләй чит шәһәрләргә, авылларга да кияү-кәләш булып китә. Шундый парларның берсе – урта яшьләрдәге Данис һәм Альбина. Пермь өлкәсенең Барда районы егете Казан кызына бер күрүдә гашыйк була һәм аны үз ягына алып китә.

– Танышу сайтларында теркәлергә һәм кияүгә чыгарга тәкъдим иткән һәркемгә «Анда нормаль кеше юк», – дип әйтә идем. Бик шикләнсәм дә, үзем сынап карарга булдым. Шул ук кичне миңа булачак ирем язды. Бер айдан соң күрештек, ике айдан соң яңадан яныма килде һәм кызым белән мине алып та китте. Казаннан 625 чакрым ераклыктагы авыл бит ул! Мине белгән һәм белмәгән кешеләр «юләрдер бу» дип уйлады. Имеш, шәһәрдән кем авылга күченә инде?! Ирем белән танышканчы дусларым миннән: «Авылга күченер идеңме?» – дип сораганнар иде. Ул вакытта мин озак уйладым, тиз генә җавап бирә алмадым. Мин дусларыма бик рәхмәтле. Алар булмаса, танышмаган да булыр идем. Ирем белән бик әйбәт яшибез. Йортны төзеп бетердек, бакча утырттык, ике ул үстерәбез, Аллага шөкер, – дип уртаклашты Альбина.

Һәм мондый мисаллар күп.

– Интернетта җитди мөнәсәбәтләр була алачагына беркайчан да ышанмадым. Ә нәтиҗәдә булачак ирем – Санкт-Петербургта, мин – Казанда. Ярты ел шулай очрашып йөрдек, аннары ул миңа тәкъдим ясады. Узган елны яз көне никах укыттык, җәй көне туй уздырдык һәм ирем белән Петербургка күчендек, – ди 26 яшьлек Диләрә Әхнәфова. – Татарча танышу сайтларының шунысы яхшы: биредә кыска вакытлы мөнәсәбәтләр өчен түгел, ә гаилә кору өчен танышалар. Тиң ярымны табуым белән шундый бәхетле мин.

Ләйсән САФИНА

Фикер

Вәсилә ШӘМСЕВӘЛИЕВА, психолог:

– Бүген онлайн танышулар популяр булса да, бу – безнең табигатебез өчен берникадәр ят күренеш. Кеше – социаль зат һәм ул аралашуга мохтаҗ. Әйе, социаль челтәрләрдә, танышу сайтларында аралашып китү күпкә җиңелрәк. Әмма без еш кына интернетта ясалма образ белән танышабыз. Танышу сайтлары аша күңелгә, кызыксынуларга, дөньяны күзаллауга туры килгән кешене табу күпкә авыррак. Ә реаль тормышта үзеңне кызыксындырган урыннарга барып, нәкъ үзеңә туры килгән кешене табарга була. Чөнки син шунда ук аның чын кыяфәтен, үз-үзен тотышын күрәсең, тавышын ишетәсең. Танышу сайтларында үзеңнеке булмаган кешеләр арасында бик озак чүпләнергә туры килә. Гомумән, интернетка танышырга кергәндә, син үзеңә нәрсә кирәген аңлап эш итәргә тиешсең.

СӘЛАМӘТЛЕК – ҮЗ КУЛЫҢДА!

Өлкәннәр тормышы

Өлкәннәргә – 1 миллион 500 мең сум! Лаеш районы башлыгы Илдус Зарипов ветераннар оешмасына елга әнә шуның кадәр акча бүлеп бирә икән. Бу акчага алар төрле чаралар уздыра, бүләкләр алалар, бәйгеләр оештыралар. Сөендерә торган гамәл.

Республиканың күп кенә районнарында хезмәтләре бәяләнмәгән өлкәннәр дә бар. Бу хакта Татарстан ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасының «Сәламәт яшәү рәвеше ярдәмендә өлкәннәрнең гомерен озайту» дип аталган «түгәрәк өстәл»ендә сөйләштеләр.

Соңгы елларда өлкәннәр актив тормыш алып бара. Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова сүзләренчә, лаеклы ялга чыккан кешеләрнең тормышын яхшырту өчен, дәүләт тарафыннан да бөтен мөмкинлекләр тудырыла.

– «Демография» илкүләм проекты кысасында өлкәннәрнең актив яшәүләрен кайгырту максатыннан, төрле чаралар уздырыла. Әби-бабайлар төрле түгәрәкләргә йөри, кемдер йөзә, берәүләр кул эше белән шөгыльләнә. Скандинавия таяклары белән йөрүчеләр дә бар. Шунысын онытмыйк: кешенең сәламәт булуының 60 проценты үзеннән тора, – ди ул. – Мине кул эше белән шөгыльләнгән кешеләр сөендерә. Бармак очлары белән нидер ясаган, әвәләгән, чиккән, бәйләгән кешеләрнең сәламәтлекләре яхшырак. Кызганыч, актив өлкәннәр арасында ирләр аз.

Дөрестән дә, парк-ишегалларында таяк белән йөрүче, йөгерүче, велосипедта җилдерүчеләрнең күбесе – хатын-кыз. Лаеш районындагы үзәк паркта скандинавия таяклары белән йөрүчеләр арасында бары тик бер ир-ат бар иде. Анысы да әлеге утырышка кунак булып Казаннан килгән.

veterany.tatarstan.ru

– Районда өлкәннәргә рәхәтләнеп ял итәргә, күңел ачарга бар мөмкинлекләр тудырылган. Әби-бабайлар – гореф-гадәтне, телне, милләтне саклаучылар алар. Район ветераннар советы җитәкчесе Лидия Грабалина нинди генә сорау белән ишек шакымасын, барысын да уңай хәл итәбез. Башкача ярамый да. Без аларга рәхмәтле, – ди Илдус Зарипов. – Олыгая барган саен сәламәтлекнең кадере арта. Соңгы вакытта яшьләргә дә хәрәкәт җитми. Тикмәгә генә, хәрәкәттә – бәрәкәт, димәгәннәр бит. Физик эш кимеде, җәяү йөрүче дә сирәк. Ә өлкәннәр бу яктан үрнәк.

Республика ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков та өлкәннәрнең үз сәламәтлегенә игътибарлы булуын әйтте.

– Алар үрнәк. Спорт белән дә шөгыльләнәләр. Хәзер шартлар җитәрлек. Паркларда төрле спорт җиһазлары тора. Йөгерәм дигән кешегә дә мөмкинлек бар. Велосипедта йөрүчегә дә юл җитә. Спорт заллары, мәдәният йортлары, китапханәләр олылар өчен һәрвакыт ачык, – ди ул. – Лаеклы ялга чыккач, кеше үзен кирәкле тоярга тиеш. Актив яшәү гомерне озайта. Безнең оешма тарафыннан төрле проектлар алып барыла. Өлкәннәр, бик теләп, «Балкыш» фестивалендә, «Ветераннар иҗаты» бәйгесендә катнаша. Актив яшәгән кеше авыруларын да, даруларын да оныта.

Даруны исә дөрес уйлар да алыштыра ала икән. Психотерапевт Марина Белоусова шулай ди.

– Телевизорны азрак ачарга, күңелсез яңалыкларны бөтенләй тыңламаска кирәк. Җылы хисләр турында оныттык. Өлкәннәр матур планнар корып яшәргә тиеш. Мисал итеп, Америкадагы бер ханымны китерәм. Ул 60 яшендә очучы булырга тели. 66 яшендә укып бетереп, беренче тапкыр оча. 83 яшенә кадәр барлыгы 7 тапкыр һавага күтәрелә. Бу мисал кешенең мөмкинлеген күрсәтә.

Марина Белоусова әйтүенчә, эте, мәчесе, абзарында малы, кош-корты булган кешеләр тизрәк терелә. Кемгәдер кирәк булуларын тою аларга тернәкләнергә ярдәм итә. Табиб лаеклы ялга чыккан кешеләргә уңай хисләр белән яшәргә, тормышның бу этабын дөрес итеп планлаштырырга киңәш бирә. «Яшькә карамагыз, күңелегезне тыңлагыз, бар да үзебездән тора», – ди ул.

Очрашуда сәламәтлеккә бәйле барлык сорауларга җавап эзләделәр. Лаеш район хастаханәсендә табиблар җитәме, өлкәннәргә игътибар бармы – барысын да сораштылар. Зарланмый үзләре. Алар беләк: теләк булса, чирне җиңәсең!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Буа үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең педиатрия бүлекчәсе палата шәфкать туташы **Абдрахманова** Талия Нурулла кызы, «ЗВЕЗДА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Уразманов** Артур Ринард улы, республиканың энергетика тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татэнерго» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – җылылык һәм электр энергиясен сату буенча директоры **Зверев** Олег Игоревич, рухи-әхлакый хәзинәләрне саклауга һәм үстерүгә, тынычлыкны һәм конфессияара татулыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен протоиерей, Рус Православие Чиркәвенең (Мәскәү Патриархаты) Чистай епархиясе Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Базарлы Матак авылының Изге Троица храмы приходы җирле православие дини оешмасы секретаре **Зиньков** Андрей Николаевич, эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы милиция майоры **Иванов** Николай Иванович, яшь буынга хәрби-патриотик тәрбия бирүгә һәм республикада ветераннар хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Әфганстан ветераннарының Россия берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы Вахитов районы бүлекчәсе идарәсе рәисе **Ишмөхәммәтов** Әнгам Миңнеәхмәт улы, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм һөнәри эшчәнлектә казанышлары өчен «Татарстан Республикасының кече бизнес лизинг компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Каюмов** Айрат Дамир улы, законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Солтанов** Мансур Марсель улы, республиканың финанс системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры **Фәйзрахманов** Марат Җәүдәт улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Гафиятов Әсгать Мәсгут улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Буа районы) **Гафиятов** Әсгать Мәсгут улына, «Элита» нәселле терлек үрчетү баш предприятиесе» акционер җәмгыяте генераль директоры (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Зарипов** Фәннур Рәфхәт улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитештерү бүлеге башлыгы **Камалиев** Госман Ганибай улына, «Павлова Тамара Ивановна» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Мамадыш районы) **Павлова** Тамара Ивановнага, «ВОСТОК-АГРО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлекчелек буенча бухгалтеры (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Фәйзуллина** Фәния Рәхмәтулла кызына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы урынбасары **Хөсәенов** Айрат Шәвкәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«БӨРЕЛЕ» ябык акционер җәмгыятенең төлке-ак төлке фермасы бригадиры (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Фролова** Галина Леонидовнага, «САБА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте сыер савучысы (Татарстан Республикасының Саба районы) **Хәсәнова** Илсөяр Гафурбай кызына, «Урал» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы сыер савучысы (Татарстан Республикасының Кукмара районы) **Хәсәнова** Нурисә Шамил кызына, «Кызыл Шәрык Агро» акционер җәмгыяте «Вахитов» терлекчелек комплексының машина белән сыер саву өлкән операторы **Шәрипова** Надежда Васильевнага **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте үзәкләштерелгән дини оешмасының «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мәдрәсәсе» һөнәри белем бирү оешмасы мөселман дини оешмасы музее мөдире **Мингалиев** Зөлфәт Салих улына, Бөтендөнья татар конгрессының республика иҗтимагый фонды Россия Федерациясе төбәкләрендәге татар иҗтимагый оешмалары белән эшләү комитеты баш референты **Садриев** Азат Алмас улына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«ТАИФ» компанияләр төркеме коллективы, 2012–2016 елларда «ТАИФ» акционерлык җәмгыятендә нефть эшкәртү буенча белгеч вазыйфасында эшләгән

Илгиз Әмил улы КӘЛИМУЛЛИНның

вафат булуы сәбәпле, әтисе – «ТАИФ-НК» акционерлык җәмгыятенең элекке генераль директоры Әмил Камил улы Кәлимуллинның авыр кайгысын уртаклаша.

Әмил Камилевич, бу авыр көннәрне кичерергә сабырлык һәм ныклык бирсен. Илгиз Әмил улының – изге күңелле, мәрхәмәтле кеше, инициативалы, тырыш хезмәткәрнең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

ЧЕБИЛӘРНЕ АЛДАП БУЛМЫЙ

Шөгыль

Киң күкрәкле, кыска аяклы. Иң яхшы чеби шундый була икән. Ә менә суны җылыны түгел, салкынны эчертергә кирәк. Арча районының Якты Көн авылында урнашкан крестьян-фермер хуҗалыгында безгә кош-корт үстерү серләре турында сөйләделәр. Фермер Рәзимә һәм Радик Бариевлар елга 120 меңнән артык чеби, 30 меңләп каз-үрдәк үстереп сата.

Якты Көн – бер урамлы авыл. Хәзер шәхси ферма урнашкан кырны моннан биш ел элек чүп баскан булган. Радик Бариев әйтүенчә, «ГАЗель»дән да биегрәк тигәнәкләр үскән. Юллар пычрак. Хәзер инде монда туфли киеп йөри торган. Моңа кадәр шофер булып эшләгән гаилә башлыгы юллы иткән, грант биргән өчен Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына рәхмәт укый.

– Заводта ун ел «КамАЗ» йөрттем. Ерак шәһәрләрдән төзелеш кирәк-яраклары ташыдым. Көтмәгәндә, җитәкче эштән куды. Хәзер аңа рәхмәттән башка сүзем юк. Болай да үз эшемне ачарга хыялланып йөргән идем. Бу очрак бер этәргеч булды, – дип сөйли 50 яшьлек Радик әфәнде. – Хатын белән киңәшләштек тә, машинага арба тагып, Питрәчкә чебигә киттем. Киров, Самара, Ульян өлкәләре, Чувашиядән алып кайтып саттык. Яңа эшкә шулай тотындык. «ГАЗель», «ЗиЛ» сатып алып, тирес, ком, таш ташыдым. Тормыш яхшырып китте. Шуннан соң кошчылык фермасы ачу турында уйлана башладык. Ниятем бәясен арзанрак итеп, кешегә күбрәк чеби сату иде. Якты Көн авылында җир алдык. Кыска вакыт эчендә торакларны төзеп куйдык. Дүрт кешедән башласак, хәзер сигез булдык. Ел дәвамында тик тормыйбыз. Үрдәген дә, казын да саткалыйбыз.

Фермада «сары йомгак»лар тәгәри. Аларның саны – 38 мең. Арада бер тәүлеклекләре дә, бер айлыклары да бар. Кемгә нинди кирәк, шуны сайлыйлар. Бәясе – 80–300 сум. Кош-кортны күпләп алучыларга министрлыктан субсидия дә каралган. Әйтик, 50–100 сатып алганда, бер чеби өчен 100 сум акча кире кайтарыла. Аксубай, Югары Ослан, Теләче, Кукмара, Балтач, Арча, Биектау районнары халкы аеруча күп килә.

Әнә Кукмараның Олыяз авылында яшәүче Сәрия апа Маликова ел саен 100 чеби алып китә икән. «Берсе дә үлми. Монда өйрәткәнчә тәрбиялим», – ди. Арчада яшәүче Нотфуллиннарның да беренче мәртәбә генә килүе түгел. Исәпләре – тавыкларын алыштыру.

– Йомык күзле булса, юньле тавык булмый. Күзен ачып, чекерәеп торырга тиеш. Белеп алабыз. Ирем – зоотехник, – ди Наилә ханым.

Кайбер көнне чират торырга да туры килә. Халык кош-корт асраудан бизмәгән, димәк. «Бөтен кешегә дәүрәгән бирергә тырышабыз, кечкенәсе үсә тора. Чебиләрне үзебездән дә, башка төбәкләрдән дә алып кайтабыз. Йомырка – чит илнеке. Италия, Төркиянеке яхшырак. Чебешләрне бер айдан да артык тоткан юк, хәзер алып бетерәләр», – диде хуҗалар.

Рәзимә әйтүенчә, чебиләр җылыны, яктылыкны ярата. Үтәли җил ярамый. Юеш булса, чирли башлыйлар. Салкын су эчерткәндә, аппетитлары яхшыра. Менә шундый хикмәте дә бар. Салкын тияр дип куркырга кирәкми. Сүзгә Радик әфәнде кушылып: «Чебине алдалап булмый. Катнаш азыкның яхшысын сайлагыз. Югыйсә туздырып, асларына түшәп бетерәчәкләр. Мин үзем дә уч төбе кадәрле чебинең болай күп ашавына ышанмый идем. Әйтик, 10 мең чебигә көнгә 2 тонна азык, 3 тонна су китә, – ди ул.

Табыш алу өчен, тыз-быз чабарга, тик тормаска кирәк, әлбәттә. Кайбер төннәре йокысыз да үтә.

– Кеше хәзер ялкауланды. Телефонда уйнап утырып кына 40–50 мең сум акча алмакчы. Тырышсаң, барысына да ирешергә мөмкин. Безнең заманда ипотека, кредит та алып булмады. Хәзер «КамАЗ» аласыңмы, башка техникамы, кибет ачасыңмы – барлык мөмкинлекләр дә бар. 70 яшьтән узган пенсионер әбиләр, бездән бройлер алып, шуны үстереп, Казанга алып барып сата. Менә шундый бизнесмен әбиләр бар, – ди Радик әфәнде.

Әлбәттә, эштән арыган чаклары да булмый түгел. Ул чакта янәшәдәге зуррак хуҗалык җитәкчеләрен искә төшерәләр икән. «Аларга бездән дә авыррак бит», – дип уйлау да туктамаска көч бирә Бариевларга. Алар – чын җир кешеләре!

Сәрия МИФТАХОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ «ТУГАН ТЕЛ» КАНАЛЫНДА

Гөлнара Тимерҗанованың тайгак юлы

Кыш. Иртән бозлы яңгыр яуган. Популяр җырчы Гөлнара Тимерҗанова, урамга чыгып, машинасын кабыза. «Кая җыендың мондый көнне, йөрмә, бөтен җирдә авария, юлда «бөке»ләр», – ди моңа күршесе. Әмма Гөлнараның шушы көнгә билгеләнгән эше бар: «Туган тел» каналы оештырган съемкада катнашу. Кешеләрне, команданы уңайсыз хәлдә калдырып булмый, өстән таш яуса да, барырга кирәк! Популяр җырчы, белгән догаларын укып, юлга кузгала. Көч-хәл белән Салих Сәйдәшев исемендәге концертлар залына килеп җитә ул. Һәм шатланып, телеканалның директоры Миләүшә Сибгатуллинага шалтырата: «Мин килдем!» Тик шатлануы иртәрәк булган шул. Салих Сәйдәшев исемендәге концертлар залына түгел, ә Салих Сәйдәшев урамындагы студиягә килергә кирәк булган!

Янгын сүндерүче җырчылар

«Туган тел» каналының милли премиясе бар. Әлеге музыкаль бүләк елга бер тапкыр тапшырыла. Бәйрәмдә яшь җырчылар Айгөл Закирҗанова һәм Гүзәл Гарәфиева да чыгыш ясарга тиеш. Тик кием, образ мәсьәләсе алдан хәл ителмәгән. Кызлар икесе дә кызыл киемнән килгән. Үч иткәндәй, чыгышлары да бер-бер артлы һәм алар алдыннан кычкырып торган кып-кызыл күлмәктән башкорт җырчысы чыгыш ясый. Образларны алдан хәл итәргә кирәк икән шул. Ул көнне җырчы кызлардан «Өч пожарный» дип көлгәннәр. Яратып инде, әлбәттә.

Илзидә Госманова макияжын әрәм итми

Телеканалның Уфада бәйрәме булырга тиеш. Казаннан популяр җырчы Илзидә Госманова да иптәше белән бергә Башкортстан башкаласына юл тота. Килеп җитүгә, әлеге дә баягы Миләүшә Сибгатуллинага шалтырата ул:

– Без килеп җиттек. Кайсы залга барыйк?

– Кая килеп җиттегез? – дип аптырый Миләүшә.

– «Туган тел» каналы бәйрәменә.

– Соң ул бит 16 декабрьдә буласы. Ә бүген 16 ноябрь!

Илзидә Госманова шунда аһ итә. Иң кызганганы – прическа һәм макияжы. Әмма Илзидә аптырап калмый: тиз генә фотограф һәм студия табып, фотосессия уза һәм хәтта бер җыр да яздырып кайта Уфа каласыннан. Уфф! Прическа һәм макияж әрәм булмады!

Әминә еламады үкереп

Әминә Әхмәтҗанова исемле бик талантлы бер бала бар. Аның башкаруындагы «Ай һәм кояш» дигән җырга клип төшерергә җыеналар. Тулган ай да, кояш бату да, таң ату да кирәк. Ә иң мөһиме – зәңгәр күлдә томан күтәрелү кадрлары. Иртәнге өчтә Казан читендәге Зәңгәр күлдә була бу хәл. Алып килгән матрасны өреп кабартып, суга җибәрәләр. Аның өстендә – Әминә. Матрасны ярга бәйләгәннәр үзе, әмма бау ычкынган. Берзаман томан эчендә Әминәле «көймә» ярдан китә башлый. Ә су салкын. Ярый әле яшь җырчының әтисе батыр кеше булып чыга. Суга сикерә дә матраска йөзеп барып җитә. «Чү, Әминә, елама, матрас батмый ул күлдә», – диярсең.

АНКЕТА

Кичә җитен чәчле малаем мәктәптән анкета сыман бер кәгазь тотып кайтты.

– Менә шушыны тутырырга куштылар, әти. Иртәгә алып барырга кирәк…

Укып карасам, күңелем йомшарып китте: мәктәп безне дә искә төшерергә вакыт тапкан! Янәсе, хөрмәтле ата-аналар, сез кем һәм кайсы өлкәдә эшлисез? Шундук кулыма каләм алдым.

– Хәзер тутырабыз аны, улым!

Тиз генә фамилиямне, исемемне һәм әтием исемен яздым, туган елымны күрсәттем һәм, «профессиягез» дигән юлга җиткәч, аксак аттай төртелеп калдым. Туктале, дим, бу нәрсә юкка гына түгелдер. Боларның мәктәбе ремонт-фәләнгә әзерләнми микән?..

«Төзүче» дип язсам, башка еллардагыча, тактасын, буявын, кадагын сорап, теңкәгә тиюләре бар, – дим, – дөресен язмасаң да әллә ничек…»

Уйлана торгач, ни булса, шул булыр, дидем дә, тәвәккәлләп, зур хәрефләр белән «ДВОРНИК» дип язып куйдым! Күзләренә бәрелеп торсын! Хәтта шундый уйның башыма төшүенә кәефем килде, чөнки дворниктан нәрсә сорасыннар? Аллага тапшырдык!

Әлбәттә, анкетаны Аллага түгел, җитен чәчле малаем кулына тоттырдым.

«ДВОРНИК» сүзе, чыннан да, күзгә бәрелеп тора икән, аны малай да күреп алды:

– Ник алай яздың, әти? Син төзүче ич…

– Күп белсәң, тиз картаерсың. Бар, укуыңа соңга каласың.

Кичен мәктәптән кайтып кергән малаем миңа бусагадан ук:

– Әти! Синнән илле себерке сорадылар! – дип кычкырды.

Әхәт САФИУЛЛИН

Үпкәсез туй

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ БУШ КӘГАЗЬГӘ КУЛ КУЙДЫРГАН

Җәй – туйлар чоры. «Ха-ха-ханә»дә туйларга бәйле кызыклы хәлләрне барларга булдык. Киләсе саннарда да безне укып барыгыз. Ә әлегә Зөлфәт Зиннуров маҗарасы. Радио ди-джее һәм телевидение журналисты булуыннан тыш, ул әле мәҗлесләр дә алып бара. Берзаман Чаллыда буласы туйда Зөлфәтне уңайсыз хәлгә калдырганнар. Мәҗлескә ЗАГС хезмәткәре килә алмаган. Сәбәбе бик җитди булган, күрәсең. Шулай да әлеге хезмәткәр каяндыр Зөлфәтнең телефонын табып, аңа шалтырата: «Үзең генә ерып чык инде, зинһар!» – ди. Ә Зиннуровның мондый эшне гомер башкарганы юк. Әмма нишләргә? Инде кәләш тә елар дәрәҗәгә җиткән. Зөлфәт аптырап тормый, тиз генә бер кызыл папка таба да шунда буш кәгазь тыгып куя. Тавыш режиссерына бераз еламсырак музыка куярга куша. Рәсми язылышу тантанасы, Аллага тапшырып, шулай башланып китә. «Мәхәббәт диңгезендә… ике кораб… ир белән хатын… аерым йөзгәннән соң… ниһаять, бергә йөзәләр… – Зөлфәт башына нинди матур сүзләр килә, шулардан җөмләләр төзи башлый. – Ике йөрәк бер йөрәк булып типкән шушы матур көндә…» «Кияү, син бу кызны алырга ризамы?» «Риза». Кыз да риза. «Алайса, менә шушында кулларыгызны куегыз». Кияү белән кәләш бер-бер артлы чип-чиста кәгазь битенә имза куя. «Ә хәзер, әйдәгез, балдаклар алышыгыз. Инде бер-берегезне котлап, үбешсәгез дә була. Шулай итеп,

сезнең никахыгыз фәлән көнне фәлән сәгатьтә Чаллы шәһәрендә рәсми рәвештә теркәлде!» «Үзем сөйлим, үземнең көләсе килә», – ди Зөлфәт. Шуннан соң бөтен кунаклар дәррәү кул чабалар, кияү белән кәләшне котлый башлыйлар. Иң кызыгы: туйдан соң берничә көн узгач, кәләш Зөлфәткә бик зур рәхмәтләрен җиткергән, кунакларның берсе дә аны-моны сизмәде, дигән. Менә шундый мәзәк хәл. Иң мөһиме: яшь гаилә бүген дә матур гына яшәп ята. Мәхәббәт диңгезендә. Ике кораб булып.

Кызык бу

БЕР ОЧРАШУ – ДҮРТ ГОМЕР

1978 елның 19 сентябрендә илебез тарихында үзенчәлекле вакыйга була. Советлар Союзын төрле елларда җитәкләгән дүрт шәхес берьюлы бер урында очраша. Ни кызык, бу күрешү алдан планлаштырылмаган. Минеральные Воды шәһәре станциясендә махсус поезд туктый. Аның эчендә – ил җитәкчесе Леонид Ильич Брежнев. Мәскәүдән Бакуга баруы. Янында ярдәмчесе дә бар – Константин Черненко, ул да – булачак генсек. Перронда аларны Юрий Андропов каршы ала. Ул вакытта ул – КГБ җитәкчесе. Якындагы Кисловодск шәһәрендә санаторийда ял итеп яткан вакыты икән. Ә янында тагын бер кеше була – яшь Михаил Горбачев. Андропов Брежневны Коммунистлар партиясенең Ставрополь крае бүлегенең Беренче секретаре Горбачев белән таныштыра. Күпмедер вакыттан соң Михаил Сергеевичны Мәскәүгә эшкә күчерәләр. Станция перронында булган бу вакыйга тарихка «Дүрт генсек очрашуы» дип кереп кала.

Мач әйткән!

Владимир ВЫСОЦКИЙ, актёр, җырчы:

– Кешедә мин яхшылык эзлим, начарлык ул болай да күренә.

Укы, студент!

Институтта көн дә укуга йөрисең. Көн дә шул бер үк хәл. Бернинди яңалык юк. Лекцияләр, конспект язу, йокы килә, күңелсез. Әмма син бер генә дәресне калдырып кара, бөтен мөһим нәрсә шул көнне була: курс эшенә темалар өләшкәннәр, җитәкчеләрне билгеләгәннәр, төркемнәргә бүлгәннәр, практик эш булган, бөтен төркемгә автомат куйганнар, ректор кереп, бөтен кешенең кулын үбеп чыккан!

ФОТОТЕСТ

Шушы мәче эчендәге ноктага күзегезне алмыйча 15 секунд карап торыгыз. Мәчене 15 секундтан соң нинди төстә күрәсез, сезнең төп сыйфатыгыз шул булыр.

Яшел төс – сез батыр.
Сары – бәхетле.
Зәңгәр – тыныч.
Көрән – усал.
Кызыл – артык ышанучан.

Май бәйрәмнәрендә халык ике төргә бүленә



Ир – баш, хатын – муен

Стюардессаларга ансат: бөтен мужиклар класслар буенча бүленгән.

~ • • • ~

Хатын-кызга төнге өчкә кадәр йөрергә башта әтисе рөхсәт итми, аннары ире.

~ • • • ~

– Син кыйммәтле шәраб сыман, еллар узган саен яхшыра гына барасың, диде миңа ирем.

– Һәм?

– Һәм базга ябып куйды.

~ • • • ~

– Безнең әти китап язды бугай, әни.

– Ник алай дисең, улым.

– Телефоннан кемгәдер «безнең роман тәмам» диде.



– Мин синнән китәм!

– Ярар.

– Син минем кебек башка кешене таба алмаячаксың!

– Тагын берәр сүз әйт әле. Һәр әйткән яңалыгың алдагысыннан яхшырак.

~ • • • ~

Кыз белән танышканчы, мин аның социаль челтәрен өйрәнәм. Мондый контентны булдырырга хәлемнән килер микән?

~ • • • ~

– Сокланам сезгә: ун ел буе кулга-кул тотынышып йөрисез.

– Ычкындырсам, берәр кирәкмәгән әйбер сатып алачак бит ул.

~ • • • ~

– Миңа хатыным бүген кофе китереп бирде һәм бер күзен кысты. Эчмәдем. Курыктым.

~ • • • ~

Эльмира дөрес юл белән китмәгәндә, аңа хәтта навигатор да: «Ну ярар, үзең кара инде», – дип әйтә.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 270

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+